**Нигезләмә**
**Иҗади конкурс һәм семинар “Татар теле – халкым теле”**

## 1. Гомуми мәгълүмат

1.1. Иҗади конкурс һәм семинарның (алга таба - Чара) төп оештыручылары Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм Сәләт яшьләр һәм балалар оешмасы. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе финанс ярдәмендә уздырыла.

1.2. Чараны оештыруда һәм уздыруда катнашучы оешмалар: Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Чувашия Республикасы Батыр муниципаль округы администрациясе, Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан фәннәр академиясе Гамәли семиотика фәнни-эзләнү институты, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, Татрастан яшьләр министрлыгының ДБУ “Сәләт” яшьләр үзәге, Татарстан региональ яшьләр фонды “Сәләт” (Талант), АНО ИЯҮ “Сәләт-Батыр”.

1.3. Чара иҗади конкурс һәм семинар формасында татар теле һәм әдәбияты һәм, шулай ук, үз фәннәрен татарча укытучы педагоглар арасында үткәрелә.

1.4. Конкурсның темасы: “Төрле фәннәрне (шул исәптән татар теле һәм әдәбиятын) татар телендә укытуда заманча технологияләр куллану” (алга таба – Проект).

1.5. Чараны уздыру урыны: “Сәләт-Батыр” ЯИҮ (Кызыл Чишмә ав., Батыр муниципаль округы, Чувашия Республикасы).

## 2. Төп идеясе

2.1. Татарлар күпләп яшәгән регионнарда татар теленең дәрәҗәсен, абруен күтәрү.

2.2. Татар яшьләрендә туган телебезгә карата тирән ихтирам хисләре тәрбияләү, аларның татар телен белүне, татар телендә сөйләшүне үзләренең намус эше итеп кабул итүенә уңай йогынты ясау.

2.3. Барлык фәннәр өлкәләрендә татар телендәге белем бирү мәйданын заманча технологияләр ярдәмендә баетып, телнең үсешен һәм кулланылышын яңа форматларда (инновацион методикалар) активлаштыру.

## 3. Максаты һәм мәсьәләләре

3.1. Мәктәпләрдә, татар халкында, аеруча, яшьләр арасында татар теле укытучыларының, үз фәннәрен татарча укытучы педагогларның абруен арттыру.

3.2. Рәсәйнең төрле регионнарында, аеруча, “Сәләт-Батыр” яшьләр үзегенә якын районнарда яшәүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына һәм башка фәнне татар телендә алып баручы педагогларга якыннан аралашу, үзара тыгыз элемтәләр булдыру, тәҗрибә бүлешү шартлары тудыру.

3.3. Балаларны һәм яшьләрне актив конкурста катнаштырып, аларда татар халкына һәм татар теленә, тарихыбызга һәм мәдәниятыбызга карата

мәхәббәт тәрбияләү, татар теленә өйрәнү, саклау, үстерүнең мөһимлеген күңелләренә сеңдерү.

3.4. Фәннәрне татар телендә укытканда (шулай ук, татар телен һәм әдәбиятын укытканда) заманча технологияләр куллануның отышлы булуын һәм татар теленең фәннәрне укыту өчен кулай тел булуын күрсәтү.

## 4. Нәтиҗәләр

4.1. Татар теле укытучыларына, гомумән, төрле фәннәрне татар телендә укытучы педагогларга да, системалы рәвештә даими очрашып тору мөмкинлеге тудыру.

4.2. Бер мәйданчыкта әлеге проблеманы уртага куеп сөйләшеп, төрле мәктәпләрдә булган мәсьәләләрнең чишелү юлларын табып, гомумиләштереп, мәктәпләр җитәкчелегенә җиткерү.

4.3. Укытучылар әлеге чарага әзерләнү чорында да, “Сәләт-Батыр”да узачак иҗади конкурс һәм семинарга әзерләнү вакытында да, бүгенге көндә бик актуаль булган заманча технологияләр, ясалма интеллект кулланып эшләү ысулларын үзләштерәчәк, бу өлкәдә консультатив ярдәм алырлык контактлар булдырачак.

4.4. Проектның читтән торып ярышу (заочный) һәм “Сәләт-Батыр” үзәгендә уздырылучы иҗади конкурс һәм семинар (очный) этапларында тупланган материаллар (эсселар, презентацияләр, аналитик һәм методик материаллар, сценарийлар, уеннар, фото-видео материаллар (QR-код белән)) чараның нәтиҗәсе буларак, бер туплама итеп эшләнәчәк.

## 5. Чараны оештыру һәм башкару тәртибе

5.1. Үз фәннәрен татар телендә укытучылар конкурсы. Темасы: “Төрле фәннәрне (шул исәптән татар теле һәм әдәбиятын) татар телендә укытуда заманча технологияләр куллану”.

Татар теленең Интернетта һәм социаль челтәрләрдә көннән-көн активрак кулланылуын искә алып, татар гимназияләрендә, татар мәктәпләрендә фәннәрне (шул исәптән, татар теле һәм мәдәниятын да) татар телендә өйрәтүдә санак технологияләре, яңа информацион технологияләр куллану, аеруча, санак уеннары һәм блогерларның мөмкинлекләрен бу максатта куллану үрнәкләре.

5.2. Уздырылу вакыты:

- читтән торып ярышу (заочный) этабы: 10 февраль-16 март, 2026 ел;
- иҗади конкурс һәм семинар (очный) этабы: 10 апрель-12 апрель, 2026 ел.

5.3. Читтән торып ярышу (заочный) этабы: форматы һәм катнашучылары.

5.3.1. Читтән торып ярышучылар түбәндәге материалларны җибәрәләр:

1. Резюме. Автобиография. *(Кушымта 1: тутыру шартлары).*
2. Санак технологияләре кулланып татар телен укыту дәресе сценарие (социаль челтәрләрне, санак уеннарын, Интернет, ясалма интеллект техологияләрен дә кертеп). *(Кушымта 2: Сценарийга таләпләр)*.

5.3.2. Материалларны җибәрү сылтама аша башкарыла: https://forms.yandex.ru/u/697b781902848f10b0a51832.

5.3.3. Катнашучылар үз фәннәрен (шул исәптән, татар теле һәм әдәбиятын

да) татар телендә укытучы педагоглар (РФ һәм чит илләрдә яшәүчеләр).

5.3.4. Читтән торып ярышу чараның ачык өлеше. Катнашучылар саны, аларның яше, яшәгән урыны һәм алар укыткан мәктәпнең кайсы ведомствога каравы мөһим түгел.

5.3.5 Читтән торып ярышу этабы нәтиҗәләре нигезендә 4 җиңүче сайлап алына.

5.3.6 Җиңүчеләр "Сәләт-Батыр" Яшьләр иҗтимагый үзәгенә "Төрле фәннәрне (шул исәптән татар теле һәм әдәбиятын) татар телендә укытуда заманча технологияләр куллану" исемле иҗади конкурста һәм семинарда катнашырга чакырыла.

5.4. Иҗади конкурс һәм семинар (очный) этабы: форматы һәм катнашучылары.

5.4.1. Иҗади конкурс һәм семинар (очный) этабының форматы:

а) Семинар: "Фәннәрне (шул исәптән, татар теле һәм әдәбиятын да) татар телендә укытуда заман таләпләре" *(аерым программа).*

б) Үз фәннәрен татар телендә укытучы педагоглар конкурсы: "Үз фәнеңне татар телендә укытканда, дәрес үткәрүдә яңа инфокоммуникацион технологияләр куллану (санак уеннары, социаль челтәрләр, Интернет, ясалма интеллект). *(Кушымта 3: конкурс шартлары).*

в) Кичке чара.

5.4.2. Конкурс читтән торып ярышта катнашып җиңүче укытучылар арасында оештырыла.

5.4.3. Катнашучылар:

Чарада 100 кеше катнаша:

- Читтән торып ярышу этабында җиңүче үз фәннәрен татар телендә укытучы педагоглар.

- Чакырылган педагоглар. Өстенлек Чувашия Республикасы Батыр районы Кызыл Чишмә авылына якын районнарнардан булган үз фәннәрен татар телендә укытучы педагогларга һәм башка регионнардан читтән торып ярышу этабында катнашкан укытучыларга бирелә.

- Чувашия мәктәпләреннән, күрше районнар һәм регионнардан, Татарстан Республикасы районнарыннан, Мари-эль, Мордовия, Чувашия республикалары, Пенза, Түбән Новгород, Ульян өлкәләре мәктәпләреннән мәктәп укучылары чакырыла.

5.4.4 Чараның иҗади конкурс һәм семинар этабында (очно) катнашу түләүсез. Финанс һәм башка чыгымнар Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Телләр комиссиясе конкурсында откан грант исәбеннән каралган. Семинар этабына (очный этап) килү өчен транспорт белән тәэмин итү каралмаган.

## 6. Чараны әзерләү һәм уздыруны оештыру эшләрен башкаручы структура

6.1. Чараны әзерләү һәм уздыру эшләрен башкару өчен Оештыру комитеты төзелә.

6.2. Оештыру комитеты составын Сәләт оешмасы проектлары җитәкчесе раслый.

## 7. Конкурста катнашучыларны бүләкләү һәм кызыксындыру чаралары

7.1 Конкурсны мөмкин кадәр күбрәк регионнарга җәелдереп, масштаблы итеп һәм укытучыларны актив катнаштырып уздыру өчен, катнашучылар һәм җиңүчеләр өчен аерым бүләкләр һәм кызыксындыру чаралары каралган *(Кушымта 4)*.

## 8. Экспертлар советы

8.1. Конкурсның заочный этабына килгән эшләрне һәм, шулай ук, очный этабында конкурсантларны һәм аларның дәресен бәяләү өчен экспертлар советы оештырыла.

8.2. Экспертлар советына тәҗрибәле һәм югары компетенцияле белгечләр чакырыла.

## 9. Материалларны куллану

9.1 Конкурс һәм семинар материаллары бер Электрон җыентык булып тупланачак.

9.2 Конкурста катнашу турыдан-туры материалларны куллануга ризалык бирүне аңлата.

## 10. Адрес һәм контактлар

10.1. Программа комитеты һәм Оештыру комитеты адресы: Сәләт Йорты (Казан ш., Островский ур., 23 йорт).

Оештыру комитеты җитәкчесе:

Алембикова Ләйлә Фәнис кызы (xat@halkimtele.org).

Сайт адресы: halkimtele.org

*Кушымта 1*

**Резюме. Автобиография (тутыру шартлары)**

**1. Резюме ике өлештән тора:**

**1.1. Стандарт формада (барлык конкурсантларга да бер формада)**

Шәхси мәгълүмат.

- Тулы исеме (исеме, фамилиясе, әтисенең исеме):
- Телефоны:
- Электрон почтасы:
- Шәхси сайтка сылтамасы:
- Яшәү урыны:
- Эш урыны, вазифа:
- Эш тәҗрибәсе:
- Белеме:
- Казанышлары, ирешелгән уңышлары:
- Өстәмә мәгълүмат (телләр белү, кызыксынулар (фән, әдәбият, спорт)):

**1.2. Ирекле формада (түбәндәге тәкъдимнәрне истә тотып языла).**

- Яңа төр технологияләр өйрәнүдә шәхси казанышлары.
- Тәҗрибәсе кайдан тупланган?
- Телгә, татар теленең байлыгына өйрәтүче чыганаклар турында язу (санак уеннары, мультипликацияләр, социаль челтәрләр, ясалма интеллект һ.б.).
- Укытуда кайсы мәгълүмати чыганаклар куллануын, кайсы чыганакларны кулланырга өйрәтүен тасвирлау.
- Укучыларга тапшырган кыйммәтләр, тәҗрибәгезне тасвирлагыз.
- Туган телебездә укытуда нинди теләк, ният, максат белән янам, ничек итеп үз өлешемне кертә алам.

**2. Автобиография эчтәлеге:**

- Туган-үскән җире турында (берничә җөмлә). Гаиләдә нинди кыйммәтләргә өйрәнеп үсүе хакында.
- Халкыбыз иҗатын кемнән, кайдан өйрәнүе.
- Әтисе-әнисе, әби-бабайларының (ике яктан да) нинди белемле, нинди эштә эшләгәннәре/эшләүләре.
- Үзенең гаиләсе турында да берничә җөмлә (әгәр гаиләсе булса): исемнәре, кайда эшлиләр (һөнәре), укыйлар (мәктәбе, уку йорты).
- Үз шәҗәрәсен белүе (ничә буын, нинди һөнәр ияләре булганнар).
- Кайсы шәхесләрне (фән, мәгариф, мәдәният һәм башка өлкәләрдән) үзенә остаз итеп күрүе хакында.
- Шәхес буларак үсешенә нинди китаплар аеруча йогынты ясады дип саный (шундый биш китапны күрсәт).
- Яраткан шөгыльләрең (хобби).
- Тормыш гыйбарәсе (девизы).
- Укытудан кала тел өйрәнү һәм өйрәтүгә нинди өлеш кертүе хакында (театр, чаралар, аланнар оештыру…).

*Кушымта 2*

**Фәнне татар телендә санак технологияләре кулланып укыту дәресе сценарие (социаль челтәрләр, санак уеннары, Интернет, ясалма интеллект һ.б.ш. технологияләрне кулланып).**

**Дәрес төзелешенә һәм эчтәлегенә карата тәкъдимнәр:**

1. Дәрес укытучының үз күзаллавын, иҗадилыгын, оештыру, төзү осталыгын чагылдыра.
2. Башлам өлешенең үзенчәлекле булуы (укучының исе китәрлек (шаккатырырлык), көтелмәгәнчә булуы, дәрес башында ук укучыны кызыксындырып, дәрес темасының проблемалы мәсьәләләрен күрсәтеп, дәрес темасына һәм дәрес эченә “баштанаяк” чумдырып тартып алып кереп китә торган).
3. Дәрестә кайсы технологияне куллану мөмкин, укучылар үзләре эшлиме, дәрес экран белән бәйләп алып барыламы, төркемнәрдәме.
4. Дәреснең үтү урыны (мәйданчыгы). Башка мөгаллимнәрне дә канатландырырлык идеяләр тәкъдим итү.
5. Дәвамлылык. Укучы әлеге технологияне дәрестән тыш та, алга таба башка фәннәр өйрәнгәндә дә куллана алу мөмкинлеге.

*Кушымта 3*

**Фәннәрен татарча укытучы педагоглар конкурсы: Бүгенге инфо-коммуникацион технологияләр (санак технологияләре, санак уеннары, социаль челтәрләр, Интернет, ясалма интеллект һ.б.) кулланып үз фәненнән татар телендә дәрес бирү (Кушымта 2 үрнәгендә).**

Конкурста читтән торып үткәрелгән ярышта җиңгән 4 укытучы үзләре әзерләгән сценарий нигезендә "Сәләт-Батыр" үзәгендә чакырылган укучыларга һәм укытучыга 40 минутлык дәрес бирәләр (Заочный этапта җиңүченең әлеге Сценарие яңартылырга мөмкин).

**Бәяләү критерийлары:**

1. Дәрес төзелешенең камиллеге. Интерактив булуы. Проблемалы ситуацияләр куелуы һәм аларның чишелеше.
2. Сөйләм теленең камиллеге, төгәллеге, укучыларга үрнәк сөйләм булуы. Төпле фикер йөртү.
3. Иҗадилык яки киресенчә төгәл кыска итеп җиткерә белү.
4. Дәреснең максаты һәм аңа ирешү дәрәҗәсе. Дәреснең эчтәлегенең байлыгы, мавыктыргыч булуы.
5. Укытучының мәгълүмат байлыгы, шул ук вакытта яңалыкка омтылышы, санак технологияләрен куллану дәрәҗәсе.
6. Мәгълүматны укучыларга җиткерә алу осталыгы.
7. Укучыларның дәрестәге күтәренке рухы, игътибары, кызыксынуы исәпләнә.

*Кушымта 4*

**Конкурста катнашучыларны бүләкләү һәм кызыксындыру чаралары.**

**А) Конкурсның читтән торып уздырылган этабында (заочно) катнашучылар өчен:**

1. Конкурста катнашучы һәр укытучыга Оргкомитет исеменнән махсус электрон сертификат тапшырыла.
2. Җиңүче булган 4 укытучыга махсус дипломнар тапшырыла. Бу хакта мәгълүмат Оргкомитет исеменнән район һәм округ администрацияләренә Рәхмәт хаты җибәрелә.
3. Конкурста катнашучыларның мәктәпләренә Оргкомитет исеменнән рәхмәт хатлары җибәрелә.

**Б) Конкурсның ЯИҮ “Сәләт-Батыр” базасында уздырылган этабында (очно) катнашучылар өчен:**

1. Конкурста катнашучы 4 укытучыга махсус номинацияләре күрсәтелгән дипломнар һәм бүләкләр тапшырыла.
2. 4 конкурсант арасында Экспертлар советы тарафыннан гран-при иясе билгеләнә һәм аңа Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры имзалаган диплом һәм махсус бүләк тапшырыла.
3. Чарада катнашучы һәр укытучы һәм балага, шулай ук семинарда катнашучыларга махсус сертификатлар тапшырыла.
4. Кызыксындыру чарасы буларак, шулай ук, Чараның логотибы төшерелгән футболкалар һәм башка атрибутлар каралган.